# САЛАВАТ КҮПЕРЕ

*Курчак театры өчен пьеса, ике бүлектә*

КАТНАШАЛАР:
Шүрәле бабай
Тәлти — тиен баласы
Бурлас — бурсык баласы
Нуяк — Куян баласы
Керпе
Ябалак
Аю абзый
Тиеннәр

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Алан. Шүрәле килеп чыга.

**Шүрәле**. Саумысез, дускайларым!.. Танылыгызмы мине? Әйе. Мин Шүрәле, урман сарыгы... Хе-хе-хе! Йонлачтыр үзем, янадыр ике күзем, кети-кети уйнарга озындыр бармакларым... Мин сезгә бүген үземнең урмандагы нәни дусларым хакында гаҗәеп бер вакыйга сөйләрмен...

Борын-борын заманнарда түгел, бүгенге көндә, җиде кат диңгез аръягында да түгел, үзебезнең урманда булды бу хәл. Менә шул урманнарда бик матур тиеннәр яши! Шул тиеннәр арасында бик чая-шук тиен баласы бар. Ә тиен баласының исеме дә үзенә туры килеп тора: Тәлти! Тәлти исемле ул тиен... *(Тиеннәр чабыша.)*

**Тәлти җыры**.

Агачтан күчеп агачка
Кем йөгерә биектә?
Кемнәр генә җитә алыр
Безнең сыман киеккә?

Агач очларыннан коштай
Очып кына чабабыз —
Гөмбәләрнең, чикләвекнең
Иң тәмлесен табабыз.

**Тиеннәр**:

Йә, кайсыгыз, кайсыгыз,
Кайсыгыз куып җитә? —
Тиенне куып җиткәнне
Бер тырыс гөмбә көтә!

**Тәлти**:

Биек агач башларында

Чикләвек кетердәтәм —
Тиен баласы Тәлтидән
Башлырак кем бар бүтән?

Кайда гөмбәнең тәмлесе?
Мөслимдәме? Әлкидә? —
Гомер ашап туймаслыгы
Тиен кызы Тәлти дә!

**Тиеннәр**:

Йә, кайсыгыз, кайсыгыз,
Кайсыгыз куып җитә —
Тәлтине куып җиткәнне
Бер тырыс гөмбә көтә!

**Шүрәле**. Борын-борын заманнарда түгел, үзебезнең урманда бурсыклар да яши. Бурсык булмаса, урман урман була димени ул! Шул бурсыклар арасында бер бурсык малае бар. Ул бурсык малаеның исеме дә үзенә бик тә ярашып тора: Бурлас! Бурлас исемле ул бурсык малае...

**Бурлас** *(чыга, җырлый)*.

Кая ул миңа җитү,
Кая мине уздыру? —
Имән төбен өн ясаган
Бурсык абзагыздыр бу!

Һич юк минем гадәтемдә
Урлашу да, юл басу.
Иң намуслы җан иясе
Бурсык улы Бурлас бу!

Исемнән һәм төсемнән
Үземнән дә канәгать —
Ник шулкадәр башлы, чибәр
Булдым икән, җәмәгать?

Миннән шаян тагын кем бар?
Юк, бүтән андый булмас! —
Бөтен урманыгызга бер
Бурсыкның улы Бурлас!

Тиеннәр Бурласның җырын тыңлап, рәхәтләнеп көләләр.

**Бурлас**. Әй-һәй, агач башындагылар, нишлисез анда?

**Тәлти**. Көләбез бит.

**Бурлас**. Көлгәнегезне ишетәм дә, нишлисез дим? Тыз да быз чабышасыз.

**Кәлти**. Ә син нишлисең?

**Бурлас**. Мин уйнарга дус эзлим.

**Тәлти**. Без дә менә кунакка чакырырга дус эзлибез.

**Бурлас**. Менә бит инде мин сезгә дус. Минем исемем Бурлас, Бурсык малае Бурлас.

**Тәлти**. Бик матур исем икән — Бурлас. Ә минеке Тәлти!

**Чәлти**. Минеке Чәлти!

**Кәлти**. Минеке Кәлти!

**Бурлас**. Тәлти, Чәлти, Кәлти, нишлисез сез?

**Тәлти**. Дусларыбызны сыйларга чикләвек, җиләк-җимеш җыябыз.

**Кәлти**. Берсекөнгә безнең Тәлтинең туган көне.

**Тәлти**. Бурсык малае Бурлас, кил минем туган көнемә. Дус булырбыз.

**Бурлас**. Рәхмәт, килермен.

**Чәлти**. Әнә тегендә чикләвеклек. Кил, яме, Бурлас!

Тиеннәр китә.

**Бурлас**. Килермен! Сау булыгыз, тиеннәр! Килерен килермен дә, ә туган көнгә ничек баралар соң әле аны? Бүләк алып баралар. Ә нәрсә алып барырга? Менә бу мәсьәлә, менә бу табышмак, менә бу башваткыч! *(Китә.)*

**Шүрәле**. Борын-борын заманнарда түгел, бүгенге көндә. Җиде кат җир астында да түгел, үзебезнең якларда куяннар да яши. Шул куяннар арасында бер наян куян баласы бар. Ул куянның исеме дә үзе кебек матур: Ну-як! Нуяк исемле ул куян кызы.

**Нуяк** *(чыга, җырлый).*

Анда да чабып китәм,
Монда да барып җитәм —
Бу урманда тагын бүтән
Кызыклар бармы икән?
Кызык эзләп йөри-йөри
Мин тәмам арып бетәм.
Бүре күрсәм, кыяклыйм,
Эт күрсәм дә, кыяклыйм,
Берсеннән дә курыкмыйча,
Һаман йөрим уйнап мин —
Һич тиктормас Куян кызы,
Һич тиктормас Нуяк мин!

Агачлар арасында җылаган тавыш ишетелә.

**Нуяк**. Әй, кем ул анда?

**Бурлас** *(чыга).* Бу мин Бурлас — бурсык малае..

**Нуяк**. Бурлас! Ә мин Нуяк. Куян кыз! Нигә җылыйсың анда? Бурлас! Кем сине рәнҗетте?

**Бурлас**. Тиен кызы Тәлти туган көненә чакырды. Ә туган көнгә бүләксез барып булмый. Бүләк эзләдем, эзләдем, ләкин табалмадым. Мин анарга... мин аңарга ниндидер... шундый бер буләк алып барырмын дигән идем...

**Нуяк**. Матур уенчыклар?

**Бурлас**. Юк...

**Нуяк**. Ә җиләк-җимешләр?

**Бурлас**. Юк, андый әйберләр бөтенесендә дә бар шул... Минем башка бер төрле бүләк бүләк итәсем килә. Тик нәрсә икәнен генә белмим...

**Нуяк**. Кайгырма, әгәр дә икәү бергә эзләсәк, һичшиксез табарбыз.

Кинәт яшен яшьни, күк күкри, яңгыр ява башлый.

**Бурлас** *(агач астына кереп)*. Чыланасың, Нуяк, кер монда?

**Нуяк**. **Бурлас**.

Яңгыр яу-яу-яу,
Урман җиләкле булсын,
Чәчәкләр гөрләп үссен,
Алма-чия, җир җиләге
Кып-кызыл булып пешсен.
Яңгыр яу-яу-яу...
Урман җиләкле булсын...

Яңгыр туктый. Салават күпере чыга.

**Бурлас** *(гаҗәпләнеп күккә карый)*. Нуяк, кара әле!

**Нуяк**. Салават күпере!

**Бурлас**. Салават күперенең бер башы урман аланына төшкән дә су эчәдер...

**Нуяк**. Ә дуганың икенче башы иске тегермән янындагы буага тоташкандыр.

**Бурлас**. Нуяк, әйдә, Тегермән буасы янына барып. Салават күпереннән буяулар алабыз да Тәлтигә бүләк итәбез!

**Нуяк**. Әйдә! *(Китәләр.)*

Хәрәкәт.

**Бурлас**. Тиен кызы Тәлти шундый матур буяуларны күргәч ничек шатланыр!

**Нуяк**. Әйе! Бу Тәлтинең туган көненә искиткеч бүләк булыр?

Иске тегермән яны.

**Бурлас** *(як-ягына каранып)*. Кая соң Салават күпере? Юк бит монда Салават күпере?

**Нуяк**. Чыннан да, кая китте икән ул, ә?

Бурлас жыры.

Вәгъдәсез булдым үземә
Торалмадым сүземдә,
Тәлти дуска бүләгемне
Табалмадым бүген дә.

**Нуяк**. Кайгырма, яңгыр яугач чыга бит ул... Җылама инде, син җылагач, минем дә җылыйсым килә... *(Икәүләп җылыйлар.)*

**Шүрәле** *(чыга)*. Исәнмесез, дусларым!

**Нуяк**. Саумысез, Шүрәле бабай!

**Бурлас**. Исәнмесез!

**Шүрәле**. Нигә күзләрегез дымлы, әллә яңгыр явып үткәнгә инде?

**Бурлас**. Без Салават күпереннән буяулар алып тиен кызы Тәлтинең туган көненә бүләк итмәкче идек...

**Нуяк**. Тик ул каядыр юкка чыкты...

**Шүрәле**. Салават күпере таң алдыннан чирәмгә төшеп ял ятә ул, дусларым. Салават күперен күрәсегез килсә, иртән иртүк торып аланга барыгыз.

**Нуяк**. **Бурлас**. Рәхмәт, Шүрәле бабай! *(Китәләр)*

**Нуяк**. Әйдә, Бурлас, кайтабыз.

**Бурлас**. Ә иртәгә иртүк торып аланга барырбыз.

Караңгы төшеп, төн килә, таң ата.

**Нуяк** *(Бурлас өне янына килеп).* Бурлас!.. Бурлас!..

**Бурлас** *(йокысыннан уяна алмый).* Мм, мм... кем бар анда?..

**Нуяк**. Бурлас, бу мин — Нуяк. Тор тизрәк!

**Бурлас**. Ә? Нәрсә бар, Нуяк?

**Нуяк**. Әйдә киттек, таң ата ич. Соңга калабыз. *(Тырысларын алып китәләр.)*

**Нуяк**. Уф, хәлләрем бетте...

Аланда үләннәргә эленеп Салават күпере йоклап ята.

**Бурлас**. Нинди матур алан!

**Нуяк**. Тсс! Кычкырып сөйләшмә, куркытырсың. Хәзер бу матур буяуларны җыеп алабыз да Тәлтигә бүләк итәбез. Бурлас. Әйдә!

Алар сәйләннәр җыя башлыйлар, ләкин тамчылар җиргә тәгәрәп төшеп юк була.

**Нуяк**. Юкка чыкты. *(Җылый.)*

**Бурлас**. Төшеп китте. Бу матур буяуларны җыеп булмый икән бит?! *(Икесе дә кайгылы,)*

Шүрәле чыга.

**Шүрәле**. Матурын матур да ул, ләкин бу матурлыкны җыеп булмый шул, кемгә дә булса бүләк итеп тә булмый. Матурлык ул барыбызныкы да. Сокланыгыз, дуслар, сокланыгыз, читтән генә карап сокланыгыз бу матурлыкка. Бурлас белән Нуяк — ике дус, тиен кызы Тәлти өчен табарлар үзләре теләгән матур бүләкне. Табарлар, һичшиксез табарлар. Бүген булмаса, иртәгә, ягъни тәнәфестән соң ук табарлар!

Тәнәфес.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

**Шүрәле** *(чыга).* Балалар! Минем нәни дусларым Бурлас белән Нуяк Тәлтинең туган көненә нindirәк бүләк бирергә икән дип бик озак уйладылар. Ләкин үзләре теләгән бүләкне таба алмадылар, чөнки күңелгә хуш килерлек бүләк табу җиңел түгел икән шул. Ә хәзер алар артыннан күзәтик, ни эшләрләр икән.

Бурлас, Нуяк моңаеп кына керәләр.

**Бурлас җыры**.

Вәгъдәсез булдым үземә,
Тор алмадым сүземдә,
Тәлти дустыма бүләкне
Табалмадым бүген дә.

**Икесе бергә**. Тәлти дускайга бүләкне табалмадык бүген дә.

**Нуяк** *(колак салып).* Тукта, кемдер килә түгелме?

Агачлар арасында аркасына кәрзин аскан Аю күренә.

**Бурлас**. Аю абзый! Аю абзый!

**Аю** *(туктап).* Ни кирәк сезгә? Ни эшләп йөрисез урманда, эшсез селкенеп-кычкырышып?

**Бурлас**. Аю абзый! Тиен баласы Тәлти туган көненә чакырган иде, тик нинди бүләк алып барырга икәнен белмибез.

**Нуяк**. Сез безгә ярдәм итә алмассыз микән, Аю абзый?

**Аю**. Ә-ә-ә! Менә нинди эш белән йөрисез икән! *(Бераз уйлап.)* Соң, туган көнгә балдан да әйбәт бүләк юк инде ул. Сез аңарга бер тәпән бал бүләк итегез.

**Нуяк** *(көлеп).* Тиеннәр бит алар бал ашамыйлар.

**Аю**. Белмим инде алайса. *(Китә башлый, тик туктап кала.)* Ә сез Керпе дустан сорап карагыз, бәлки, ул беләдер. *(Китә.)*

Нуяк белән Бурлас Керпене эзләп китәләр. Юлда йомгак кебек чорналган Керпе күренә.

**Нуяк**. Керпе дус! Керпе дус!

**Бурлас**. Курыкма инде, бу бит без: Нуяк та Бурлас.

**Керпе**. Ә, сез икәнсез әле бу.

**Бурлас**. Керпе дус, тиен баласы Тәлти туган көненә чакырган иде, син белмисеңме, ниндирәк бүләк алып барсаң әйбәт булыр икән?

**Керпе**. Һе! Кипкән гөмбә белән алмадан да яхшы бүләк булмый ул. Сез аңарга шуларны бүләк итегез.

**Нуяк**. Гөмбә белән алма аларның үзләрендә дә күп.

**Бурлас**. Безнең аңарга бирәр шундый менә... менә шундыйрак... бүләк бирәсе килгән иде...

**Керпе**. Шундыйрак... шундыйрак... нинди бүләк була ул шундыйрак бүләк? Ә сез аны Ябалак түтидән сорап карагыз. Аңардан башка моны бирәү дә белмәс. *(Китеп бара,)*

Нуяк, Бурлас Ябалакны эзләп китәләр. Ул яши торган агач куышы янына килеп чыгалар.

**Икесе бергә**. Ябалак түти! Ябалак түти! *(Куышта Ябалак күренә. )*

**Ябалак**. У-һу. У-һу! Кем бар монда? Кем йөри? *(Карангалый, Бурлас белән Нуяк куркып дәшмиләр, Ябалак киредән куышына кереп китә. Нуяк белән Бурласның башка чаралары булмагач яңадан Ябалакны чакыралар.)*

**Ябалак** *(чыгып Бурлас белән Нуякны күрә).* Ә-ә-ә! Менә кемнәр йөри икән әле! Ни эшләп йөрисез эш бүлдереп? *(Кире кереп китмәкче.)*

**Бурлас**. Ябалак түти, белмисезме, тиен баласы Тәлти туган көненә чакырган иде.

**Ябалак**. Ә, Туган көн. Беләм мин, ник белмәскә! Туган көн ул бик матур бәйрәм. Ул көнне бик күп кунаклар җыела. Ул елына бер тапкыр була, ә кайвакытта берничә тапкыр уздыручылар да була.

**Нуяк**. Без сездән ниндирәк бүләк алып барыйк икән дип сорыйбыз.

**Ябалак**. Ә, бүләк! Туган көнгә бик күп төрле бүләкләр алып киләләр. Мин үземнең бүләк биргәнемне хәтерләмим, ә бүләк бирүләрен бик тә

яратам. Бүләкләр бик күп төрле булалар: ашый торганы, кия торганы, эчә торганы, ишетә торган, утыра торган, ята торган...

**Бурлас**. Я инде, Ябалак түти! Без бит сездән нindirәk бүләк алып барырга дип сорыйбыз.

**Ябалак**. Нindirәk бүләк, нindirәk бүләк?!. Соң әйттем бит инде. Аңламасагыз да, аңламассыз икән. Я, ярый, минем сезнең белән буш сүз сөйләшеп торырга вакытым юк. Әнә Шүрәле бабагыз Шурулла янына барыгыз, ул — урман сарыгы, бик оста төрле-төрле хикмәтләр уйлап табарга. *(Керeп китә.)*

Нуяк белән Бурлас аптырашта калып. Шүрәлене эзләп китәләр, баштагы аланга кире әйләнеп кайталар. Шүрәле керә.

**Бурлас**. Шүрәле бабай! Без бөтен урманны әйләнеп, барысыннан да сорап чыктык...

**Нуяк**. Тик берәү дә безнең күңелгә ошаган, тик туган көндә генә бирә торган бүләкне әйтә алмады.

**Бурлас**. Без яңадан шушы аланга, сезнең янга әйләнеп кайттык. Тәлтинең туган көненә бүләксез барып булмый бит инде.

**Нуяк**. Салават күперендәге матур буяуларны да бүләк итеп булмады...

**Шүрәле**. Мин хәзер дустыгызны шатландырыр өчен нindirәk бүләк эзләгәнегезне аңладым бугай. Дусларым, бәлки безнең гүзәл урманның үзендә сез теләгән бүләкне табып буладыр. Карагыз әле як-ягыгызга.

**Нуяк** *(чәчәкләргә игътибар итеп)*, Чәчәк!? *(Аларны өзеп җыя.)* Салават күпере кебек төрле чәчәкләр...

**Бурлас**. Әгәр шушы чәчәкләрдән такыя үрсәк?!

**Нуяк**. Әйе, бу искиткеч гаҗәеп бүләк булыр. Әйдә, чәчәкләр җыеп такыя үрәбез! *(Бурлас белән Нуяк чәчәкләр җыеп такыя үрәләр.)*

**Шүрәле**. Үз кулларың белән ясаган бүләктән дә гаҗәеп бүләк булмый шул ул.

**Нуяк**. Әйе, Шүрәле бабай, без үзебез теләгән бүләкне таптык. Рәхмәт сезгә!

Сәхнәгә тиеннәр чыга.

**Нуяк, Бурлас**. Тәлти дускай! Сине чын күңелебездән, туган көнең белән котлыйбыз!

**Тәлти**. Рәхмәт сезгә, дусларым! Бу искиткеч бүләк?

Яңгыр ява башлый. Салават күпере чыга. Барысы да аны күреп шатланалар.

**Нуяк**. Нинди матур салават күпере!

**Бурлас**. Салават күпере ул күкнең такыясы!

**Тәлти**. Ә минем такыя — нәкъ Салават күпере.

**Шүрәле**. Дуслар! Салават күпере дә Тәлтине туган көне белән, ә сезне — Бурлас һәм Нуяк, шундый искиткеч, гаҗәеп, гүзәл бүләгегез белән котлый.

Җыр башлана. Җыр барышында такыя үреп барысы да такыя кия. Салават күпере турында җыр.

И Салават күпере яна! —

Бер төсендә — каен яктысы,
Бер төсендә — күлләр чагылышы,
Бер төсендә—таңнар балкышы.

И Салават күпере яна! —
Чәчәкләрдән төсләр алгандыр,
Без яшәгән болын өсләренә
Күктән төсле нурлар тамгандыр.

И Салават күпере яна!
Балкышлары күлдә чагыла —
Гөл таҗына кунган һәр тамчыда
Бәхетле таң балкып кабына.

Таңга карап гөлләр күтәрелә,
Таңга карап гөлләр ачыла —
Мең салават күперләре яна
Җиргә төшкән һәрбер тамчыда!

**Нуяк** *(кулына такыя тотып).* Шүрәле бабай! Менә бу такыя бездән сиңа бүләк.

**Шүрәле** *(такыяне киеп).* Рәхмәт сезгә, дусларым!

**Тәлти**. Ә хәзер, әйдәгез, барыгыз да минем туган көнемә рәхим итегез! Шүрәле бабай, сез дә калмагыз!

Барысы да китәләр.

**Шүрәле**. Рәхмәт, килермен! *(Тамашачыларга.)* Дусларым! Менә шушы була инде минем сезгә сөйләргә теләгән гаҗәеп хәлләр. Ә хәзергә, хушыгыз, мин дә туган көнгә киттем! *(Китә.)*

*Серле алан, Тат. кит. нәшр., 1991.*